ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Базарлы Матак авыл җирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Базарно-Матакского сельского
поселения
Алькеевского муниципального
района

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Базарлы Матак авылы, Крайнов
урамы, 94 й.
Тел./факс 8(84346) 20071

Адрес:422888, РТ, Алькеевский
район, с. Базарные Матаки, ул.
Крайнова, д.94
тел./факс 8(84346) 20071

# КАРАРЫ

**2021 елның 20 март** **5№**

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы "Җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта нигезендә **6424,98** сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Базарлы Матак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Базарлы Матак авыл җирлегенең
Башкарма комитет җитәкчесе: Ф. Ф. Фэттахов

Базарлы Матак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 мартнын 5 номерлы карарына 1 нче кушымта

Базарлы Матак авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б№ | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3700,80 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 1336,39 |
| 4. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1387,79 |
| | Барлыгы: | 6424,98 |

Базарлы Матак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 мартнын 5 номерлы карарына 2 нче кушымта

Базарлы Матак авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б№ | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү(төрү, киендерү) | 1234,23 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2461,43 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка китерү | 1336,39 |
| 5. | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 1392,93 |
| | Барлыгы: | 6424,98 |